| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ<br>«МУКМИН-КАРАТАЙСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«МӨЭМИН-КАРАТАЙ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

---

**КАРАР**

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Мөэмин-Каратай авыл җирлеге составына керүче Мөэмин-Каратай торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

13 ноябрь 2020 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2020 елның 13 ноябрендә «2021 елда Лениногорск муниципаль районының районы Мөэмин-Каратай авыл җирлеге составына керүче Мөэмин-Каратай торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 һәм 2 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучылары, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннары, тыл хезмәтчәннәреннән тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә риза буласызмы?" соравы буенча үткән халык җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде, аның нигезендә алынган средстволарны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү кирә:

- авыл җирлеге торак пунктлары чикләрендә юлларны карап тоту
- Мөэмин-Каратай авылы юлларында чокырларны ремонтлау.

« ӘЙЕ ЮК».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре беркетмәсе нигезендә:
Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 215 кеше, 118 кеше тавыш бирүдә катнашкан.
Гражданнар җыенында катнашучыларның тавыш бирү нәтиҗәләре түбәндәгечә билгеләнде:
-“Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 1118 кеше тавыш бирде;
-җыенда катнашучы 0 кеше “Юк” позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар бирде:
Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Мөэмин-Каратай авыл җирлеге составына керүче Мөэмин-Каратай пунктында гражданнар җыены узды, аның нәтиҗәләре дөрес дип таныргa.

1. «2021 елда Лениногорск муниципаль районының районы Мөэмин-Каратай авыл җирлеге составына керүче Мөэмин-Каратай торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 һәм 2 төркем инвалидлар, Бөек Ватан

сугышы ветераннары һәм катнашучылары, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннары, тыл хезмәтчәннәреннән тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә риза буласызмы?" соравы буенча үткән халык җыены карарын, аның нигезендә алынган средстволарны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү кирә:

- авыл җирлеге торак пунктлары чикләрендә юлларны карап тоту
- Мөэмин-Каратай авылы юлларында чокырларны ремонтлау - кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны Мөэмин-Каратай авылы, Механизаторлар урамы 31Б адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендында урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында "Авыл җирлекләре" бүлегендә (leninogorsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

"Мөэмин-Каратай авыл җирлеге"
Муниципаль берәмлеге башлыгы
вазифаларын башкаручы Г.Г.Хәкимов